РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**Тенишевского**
**городского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ТЕНЕШ**
**штп. җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, 8,пгт. Тенишево 422839
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128 ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

Ленина урамы, 8,Тенеш штп., 422839,
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128 ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 16 октябре № 1

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап билгеләргә:
- 2020 елның 2 ноябрендә 16.00 сәгатькә Пионер һәм Калинин урамнары өчен;
- 2020 елның 3 ноябрендә 16.00 сәгатькә Чернышевский, Бакча, Ленин, Горняков, Яр буе урамнары өчен.

2. Гражданнар җыенына куела торган мәсьәләне расларга:
«2021 елда үзара салым кертүгә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), 300 (өч йөз)

сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- **Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

  - Калинин урамы 1 йорттан башлап, Пионер урамы 3 йортка кадәрге арада юл участогын ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Пионер ур., 18 йорт, шулай ук кабул ителгән көннән алып 5 (биш) көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы рәисе И.Т.Гыйниятов